ГЛАВА
СТЕПНОШЕНТАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
КЫР ШОНТАЛЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛАГЫ

с.Степная Шентала

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

10.11.2021 — №4

«Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Алексеевск муниципаль районының
Кыр Шонталысы авыл җирлегенең Кече Кызылъяр
авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»
Кыр Шонталысы авыл җирлеге башлыгы карарын
гамәлдән чыгару хакында

«Татарстан Республикасында яңа коронавируслы инфекция таралуны булдырмау чаралары турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 19 мартындагы 208 номерлы карарына үзгәреш кертү хакында» 2021 елның 28 октябрендәге 1006 номерлы ТР МК карарын исәпкә алып, яңа коронавирус инфекциясе таралуны булдырмау максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. «Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Алексеевск муниципаль районының Кыр Шонталысы авыл җирлегенең Кече Кызылъяр авылында гражданнар җыенын билгеләү турында» 2021 елның 30 октябрендәге 2 номерлы Кыр Шонталысы авыл җирлеге башлыгы карарын гамәлдән чыгарырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында, Кыр Шонталысы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Алексеевск муниципаль районының**
**Кыр Шонталысы авыл җирлеге башлыгы** — **Ф.Я. Хәмәдиев**